КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 22 апрель г.Казань № 502

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2017 ел, 13 июль, 485 нче карары белән расланган Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2017 ел, 13 июль, 485 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче, 2023 ел, 05 сентябрь, 1076 нчы, 2024 ел, 10 апрель, 246 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Үз эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә, 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар - социаль проблемаларны хәл итүгә, Россия Федерациясендә гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне, шулай ук «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмалар (сәяси партияләр булган иҗтимагый оешмалардан, дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин